ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
02.07.2025

**К А Р А Р**
№ 548

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2023 елның 21 февралендәге 295 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гражданнары гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2023 елның 21 февралендәге 295 номерлы карарына (19.12.2023 № 1914 редакциясендә) үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Шулай ук никахлашу турында таныклык нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнгән, ирнең (хатынның) беренче (башка) никахында туган балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләве алынмый.

Әгәр ата-ана түләвеннән азат итү өчен нигезләр туктатылса, ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта мәгариф учреждениесенә нигезләр туктатылган көннән алып өч эш көне эчендә хәбәр итәргә тиеш».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хакимуллин